**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**СОВЕТ**

**Старочелнинского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Әлки муниципаль районы**

**Иске Чаллы авыл Жирлеге**

**СОВЕТЫ**

Адрес: 422876, РТ, с. Старые Челны, ул. Центральная, 20
тел: : 8 (84346) 79-4-53

Адресы: 422876, РТ, Иске Чаллы авылы, Үзәк ур. 20
факс: 8 (84346) 79-4-53

**РЕШЕНИЕ** **Иске Чаллы авылы** **КАРАР**

2025 елның 17 июнендәге № 112А

**Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында**

“Россия Федерацисе гражданнары сайлау хакукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 105 статьясындагы 1 өлеше белән 21-ТРЗ, “Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 12 нче статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге Советы **кабул итте:**

**1.**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының бишенче чакырылыш Иске Чаллы авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләрергә.

**2.** Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасының хокуки мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгару (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының “Интернет” телекоммуникацион-мәгълүмат челтәрендәге рәсми сайтында (https://alkeevskiy.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Адреслары:

Иске Чаллы авылы, Үзәк урам, 20 нче йорт (административ бина);

Яңа Чаллы, Советская ур., 19нчы йорт ( авыл мәдәният йорты бинасы).

**3.** Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
муниципаль берәмлек башлыгы,
Иске Чаллы авыл җирлеге
Советы рәисе

Р.К.Гарипов